**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об утверждении Положения о согласовании и утверждении уставов казачьих обществ, создаваемых (действующих) на территории Республики Татарстан

Руководствуясь пунктами $3^{6-2}$ и $3^{6-3}$ Указа Президента Российской Федерации от 15 июня 1992 года № 632 «О мерах по реализации Закона Российской Федерации «О реабилитации репрессированных народов» в отношении казачества», в соответствии с Типовым положением о согласовании и утверждении уставов казачьих обществ, утвержденным приказом Федерального агентства по делам национальностей от 6 апреля 2020 года № 45, **постановляю**:

1. Утвердить прилагаемое Положение о согласовании и утверждении уставов казачьих обществ, создаваемых (действующих) на территории Республики Татарстан.

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его официального опубликования.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
25 февраля 2022 года
№ УП-166

Утверждено
Указом Президента
Республики Татарстан

от «25» февраля 2022 года

№ УП-166

**Положение**
**о согласовании и утверждении уставов казачьих обществ, создаваемых (действующих) на территории Республики Татарстан**

1. Настоящее Положение определяет перечень документов, необходимых для согласования Президентом Республики Татарстан уставов казачьих обществ, указанных в пунктах $3^4$ и $3^5$ Указа Президента Российской Федерации от 15 июня 1992 года № 632 «О мерах по реализации Закона Российской Федерации «О реабилитации репрессированных народов» в отношении казачества» (далее – Указ Президента Российской Федерации), сроки и порядок их представления и рассмотрения, порядок принятия решений о согласовании уставов казачьих обществ, указанных в пунктах $3^4$ и $3^5$ Указа Президента Российской Федерации, а также порядок принятия решений об утверждении уставов казачьих обществ, указанных в пунктах $3^{2-4}$ и $3^3$ Указа Президента Российской Федерации.

2. Президент Республики Татарстан согласовывает:

уставы окружных (отдельских) казачьих обществ, создаваемых (действующих) на территориях двух и более субъектов Российской Федерации, одним из которых является Республика Татарстан;

уставы войсковых казачьих обществ, осуществляющих деятельность на территориях двух и более субъектов Российской Федерации, одним из которых является Республика Татарстан.

3. Согласование уставов казачьих обществ осуществляется:

после принятия учредительным собранием (кругом, сбором) решения об учреждении казачьего общества;

после принятия высшим органом управления казачьего общества решения об утверждении устава этого казачьего общества.

4. Для согласования устава действующего казачьего общества атаман этого казачьего общества в течение 14 календарных дней со дня принятия высшим органом управления казачьего общества решения об утверждении устава указанного казачьего общества направляет Президенту Республики Татарстан представление о согласовании устава казачьего общества.

К представлению о согласовании устава действующего казачьего общества прилагаются:

копии документов, подтверждающих соблюдение требований

к порядку созыва и проведения заседания высшего органа управления казачьего общества, установленных главами 4 и 9[1] Гражданского кодекса Российской Федерации и иными федеральными законами в сфере деятельности некоммерческих организаций, а также уставом казачьего общества;

копия протокола заседания высшего органа управления казачьего общества, содержащего решение об утверждении устава этого казачьего общества;

устав казачьего общества в новой редакции.

5. Для согласования устава создаваемого казачьего общества лицо, уполномоченное учредительным собранием (кругом, сбором) создаваемого казачьего общества (далее – уполномоченное лицо), в течение 14 календарных дней со дня принятия учредительным собранием (кругом, сбором) решения об учреждении казачьего общества направляет Президенту Республики Татарстан представление о согласовании устава казачьего общества.

К представлению о согласовании устава создаваемого казачьего общества прилагаются:

копии документов, подтверждающих соблюдение требований к порядку созыва и проведения заседания учредительного собрания (круга, сбора) казачьего общества, установленных главами 4 и 9[1] Гражданского кодекса Российской Федерации и иными федеральными законами в сфере деятельности некоммерческих организаций;

копия протокола учредительного собрания (круга, сбора), содержащего решение об утверждении устава казачьего общества;

устав казачьего общества.

6. До направления Президенту Республики Татарстан устав казачьего общества подлежит согласованию с атаманом иного казачьего общества, а именно:

устав окружного (отдельского) казачьего общества, создаваемого (действующего) на территориях двух и более субъектов Российской Федерации, одним из которых является Республика Татарстан, – с атаманом войскового казачьего общества (если войсковое казачье общество осуществляет деятельность на территориях субъектов Российской Федерации, на которых создаются (действуют) названные казачьи общества);

устав войскового казачьего общества, осуществляющего деятельность на территориях двух и более субъектов Российской Федерации, одним из которых является Республика Татарстан, – с атаманом Всероссийского казачьего общества.

В последующем к представлению о согласовании устава казачьего общества прилагается заверенная подписью атамана казачьего общества либо уполномоченного лица копия письма о согласовании устава казачьего общества соответствующими атаманами иных казачьих обществ, указанных в абзацах втором и третьем настоящего пункта.

7. Указанные в пунктах 4 и 5 настоящего Положения копии документов

должны быть заверены подписью атамана казачьего общества либо уполномоченного лица. Документы (копии документов), содержащие более одного листа, должны быть прошиты, пронумерованы и заверены подписью атамана казачьего общества либо уполномоченного лица на обороте последнего листа на месте, предназначенном для прошивки.

8. Рассмотрение представленных для согласования устава казачьего общества документов и принятие решения о согласовании либо об отказе в согласовании устава казачьего общества осуществляется Президентом Республики Татарстан в течение 14 календарных дней со дня поступления указанных документов.

О принятом решении Президент Республики Татарстан уведомляет атамана казачьего общества либо уполномоченное лицо в письменной форме путем подписания соответствующего служебного письма не позднее 14 календарных дней с даты принятия указанного решения.

В случае принятия решения об отказе в согласовании устава казачьего общества в уведомлении указываются основания, послужившие причиной для принятия такого решения.

9. Основаниями для отказа в согласовании устава действующего казачьего общества являются:

несоблюдение требований к порядку созыва и проведения заседания высшего органа управления казачьего общества, установленных главами 4 и $9^1$ Гражданского кодекса Российской Федерации и иными федеральными законами в сфере деятельности некоммерческих организаций, а также уставом казачьего общества;

непредставление или представление неполного комплекта документов, предусмотренных пунктом 4 настоящего Положения, несоблюдение требований к их оформлению, порядку и сроку представления;

наличие в представленных документах недостоверных или неполных сведений.

10. Основаниями для отказа в согласовании устава создаваемого казачьего общества являются:

несоблюдение требований к порядку созыва и проведения заседания учредительного собрания (круга, сбора) казачьего общества, установленных главами 4 и $9^1$ Гражданского кодекса Российской Федерации и иными федеральными законами в сфере деятельности некоммерческих организаций;

непредставление или представление неполного комплекта документов, предусмотренных пунктом 5 настоящего Положения, несоблюдение требований к их оформлению, порядку и сроку представления;

наличие в представленных документах недостоверных или неполных сведений.

11. Отказ в согласовании устава казачьего общества не является препятствием для повторного направления Президенту Республики Татарстан представления о согласовании устава казачьего общества и документов, предусмотренных пунктами 4 и 5 настоящего Положения, при условии

устранения оснований, послуживших причиной для принятия указанного решения.

Повторное представление о согласовании устава казачьего общества и документов, предусмотренных пунктами 4 и 5 настоящего Положения, и принятие по этому представлению решения осуществляются в порядке, предусмотренном пунктами 6–10 настоящего Положения.

Количество повторных направлений представления о согласовании устава казачьего общества и документов, предусмотренных пунктами 4 и 5 настоящего Положения, не ограничено.

12. Президент Республики Татарстан утверждает:

уставы районных (юртовых) казачьих обществ, создаваемых (действующих) на территориях двух и более муниципальных районов, муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан;

уставы окружных (отдельских) казачьих обществ, создаваемых (действующих) на территории Республики Татарстан.

13. Утверждение уставов районных (юртовых) казачьих обществ, создаваемых (действующих) на территориях двух и более муниципальных районов, муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан, осуществляется после согласования с главами соответствующих муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан, а также с атаманом окружного (отдельского) казачьего общества (если окружное (отдельское) казачье общество осуществляет деятельность на территории Республики Татарстан, на которой создаются (действуют) названные казачьи общества).

14. Утверждение уставов окружных (отдельских) казачьих обществ, создаваемых (действующих) на территории Республики Татарстан, осуществляется после их согласования с атаманом войскового казачьего общества (если войсковое казачье общество осуществляет деятельность на территории Республики Татарстан, на которой создаются (действуют) названные казачьи общества).

15. Для утверждения устава действующего казачьего общества атаман этого казачьего общества в течение пяти календарных дней со дня получения согласованного устава казачьего общества направляет Президенту Республики Татарстан представление об утверждении устава казачьего общества.

К представлению об утверждении устава казачьего общества прилагаются:

копии документов, подтверждающих соблюдение требований к порядку созыва и проведения заседания высшего органа управления казачьего общества, установленных главами 4 и 9[1] Гражданского кодекса Российской Федерации и иными федеральными законами в сфере деятельности некоммерческих организаций, а также уставом казачьего общества;

копия протокола заседания высшего органа управления казачьего

общества, содержащего решение об утверждении устава этого казачьего общества;

копии писем о согласовании устава казачьего общества должностными лицами, указанными в пунктах 13 и 14 настоящего Положения;

устав казачьего общества на бумажном носителе и в электронном виде.

16. Для утверждения устава создаваемого казачьего общества уполномоченное лицо в течение пяти календарных дней со дня получения согласованного устава казачьего общества направляет Президенту Республики Татарстан представление об утверждении устава казачьего общества.

К представлению об утверждении устава казачьего общества прилагаются:

копии документов, подтверждающих соблюдение требований к порядку созыва и проведения заседания учредительного собрания (круга, сбора) казачьего общества, установленных Гражданским кодексом Российской Федерации и иными федеральными законами в сфере деятельности некоммерческих организаций;

копия протокола учредительного собрания (круга, сбора), содержащего решение об утверждении устава казачьего общества;

копии писем о согласовании устава казачьего общества должностными лицами, указанными в пунктах 13 и 14 настоящего Положения;

устав казачьего общества на бумажном носителе и в электронном виде.

17. Копии документов, указанные в пунктах 15 и 16 настоящего Положения, должны быть заверены подписью атамана казачьего общества либо уполномоченного лица. Документы (их копии), за исключением документов в электронном виде, содержащие более одного листа, должны быть прошиты, пронумерованы и заверены подписью атамана казачьего общества либо уполномоченного лица на обороте последнего листа на месте прошивки.

18. Рассмотрение документов, указанных в пунктах 15 и 16 настоящего Положения, и принятие решения об утверждении либо об отказе в утверждении устава казачьего общества осуществляется Президентом Республики Татарстан в течение 30 календарных дней со дня поступления документов.

О принятом решении Президент Республики Татарстан уведомляет атамана казачьего общества либо уполномоченное лицо в письменной форме путем подписания соответствующего служебного письма не позднее 14 календарных дней с даты принятия указанного решения.

В случае принятия решения об отказе в утверждении устава казачьего общества в уведомлении указываются основания, послужившие причиной для принятия такого решения.

Утверждение устава казачьего общества оформляется распоряжением Президента Республики Татарстан, копия которого направляется атаману казачьего общества либо уполномоченному лицу одновременно

с уведомлением, указанным в абзаце втором настоящего пункта.

19. Основаниями для отказа в утверждении устава действующего казачьего общества являются:

несоблюдение требований к порядку созыва и проведения заседания высшего органа управления казачьего общества, установленных Гражданским кодексом Российской Федерации и иными федеральными законами в сфере деятельности некоммерческих организаций, а также уставом казачьего общества;

непредставление или представление неполного комплекта документов, предусмотренных пунктом 15 настоящего Положения, несоблюдение требований к их оформлению, порядку и сроку представления;

наличие в представленных документах недостоверных или неполных сведений.

20. Основаниями для отказа в утверждении устава создаваемого казачьего общества являются:

несоблюдение требований к порядку созыва и проведения заседания учредительного собрания (круга, сбора) казачьего общества, установленных Гражданским кодексом Российской Федерации и иными федеральными законами в сфере деятельности некоммерческих организаций;

непредставление или представление неполного комплекта документов, предусмотренных пунктом 16 настоящего Положения, несоблюдение требований к их оформлению, порядку и сроку представления;

наличие в представленных документах недостоверных или неполных сведений.

21. Отказ в утверждении устава казачьего общества не является препятствием для повторного направления Президенту Республики Татарстан представления об утверждении устава казачьего общества и документов, предусмотренных пунктами 15 и 16 настоящего Положения, при условии устранения оснований, послуживших причиной для принятия указанного решения.

Повторное представление об утверждении устава казачьего общества и документов, предусмотренных пунктами 15 и 16 настоящего Положения, и принятие по этому представлению решения осуществляются в порядке, предусмотренном пунктами 17–20 настоящего Положения.

Количество повторных направлений представления об утверждении устава казачьего общества и документов, предусмотренных пунктами 15 и 16 настоящего Положения, не ограничено.

22. На титульном листе устава казачьего общества, представляемого Президенту Республики Татарстан на согласование либо утверждение, рекомендуется предусматривать грифы согласования либо утверждения устава соответственно.

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы территориясендә төзелә торган (гамәлдәге) казак җәмгыятьләре уставларын килештерү һәм раслау турында нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Президентының «Казак җәмгыятьләренә карата «Репрессияләнгән халыкларны аклау турында» Россия Федерациясе Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 1992 елның 15 июнендәге 632 номерлы Указының $3^{6-2}$ һәм $3^{6-3}$ пунктлары нигезендә, Милләтләр эшләре буенча федераль агентлыкның «Казак җәмгыятьләре уставларын килештерү һәм раслау турында өлге нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 6 апрелендәге 45 номерлы боерыгы белән расланган Казак җәмгыятьләре уставларын килештерү һәм раслау турында өлге нигезләмәгә таянып, **карар бирәм:**

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы территориясендә төзелә торган (гамәлдәге) казак җәмгыятьләре уставларын килештерү һәм раслау турында нигезләмәне расларга.

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 25 февраль
№ ПУ-166

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның «25» февралендәге
ПУ-166 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы территориясендә төзелә торган (гамәлдәге) казак җәмгыятьләре уставларын килештерү һәм раслау турында нигезләмә**

1. Әлеге нигезләмәдә Россия Федерациясе Президентының «Казак җәмгыятьләренә карата «Репрессияләнгән халыкларны аклау турында» Россия Федерациясе Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 1992 елның 15 июнендәге 632 номерлы Указының (алга таба – Россия Федерациясе Президенты Указы) $3^4$ – $3^5$ пунктларында күрсәтелгән казак җәмгыятьләре уставларын Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан килештерү өчен кирәкле документлар исемлеге, аларны бирү һәм карап тикшерү сроклары һәм тәртибе, Россия Федерациясе Президенты Указының $3^4$ һәм $3^5$ пунктларында күрсәтелгән казак җәмгыяте уставларын килештерү турында карарлар кабул итү тәртибе, шулай ук Россия Федерациясе Президенты Указының $3^{2-4}$ һәм $3^3$ пунктларында күрсәтелгән казак җәмгыятьләре уставларын килештерү турында карарлар кабул итү тәртибе билгеләнә.

2. Татарстан Республикасы Президенты түбәндәгеләрне килештерә:

Россия Федерациясенең шулардан берсе Татарстан Республикасы булган ике һәм берничә субъекты территориясендә төзелә торган (гамәлдәге) округ (бүлек) казак җәмгыятьләре уставларын;

Россия Федерациясенең шулардан берсе Татарстан Республикасы булган ике һәм берничә субъекты территориясендә эшчәнлек алып барган гаскәри казак җәмгыятьләренең уставларын.

3. Казак җәмгыятьләре уставларын килештерү түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

гамәлгә кую җыелышы (круг, җыен) тарафыннан казак җәмгыятен гамәлгә кую турында карар кабул ителгәннән соң;

казак җәмгыятенең югары идарә органы тарафыннан әлеге казак җәмгыятенең уставын раслау турында карар кабул ителгәннән соң.

4. Гамәлдәге казак җәмгыятенең уставын килештерү өчен әлеге казак җәмгыяте атаманы казак җәмгыятенең югары органы тарафыннан әлеге казак җәмгыятенең уставын раслау турында карар кабул ителгән көннән 14 календарь көн дәвамында Татарстан Республикасы Президентына казак җәмгыяте уставын килештерү турында тәкъдимнамә җибәрә.

Гамәлдәге казак җәмгыяте уставын килештерү турында тәкъдимнамәгә түбәндәгеләр теркәп бирелә:

казак җәмгыяте югары идарә органының утырышын чакыруга һәм уздыруга Россия Федерациясе Граждан кодексының 4 һәм 9[1] бүлекләрендә һәм коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеге өлкәсенә кагылышлы башка федераль законнарда, шулай ук казак җәмгыяте уставында билгеләнгән таләпләрнең үтәлүен раслый торган документлар күчермәләре;

казак җәмгыяте югары идарә органы утырышының әлеге казак җәмгыяте уставын раслау турындагы карары кергән беркетмәсенең күчермәсе;

казак җәмгыятенең яңа редакциядәге уставы.

5. Төзелә торган казак җәмгыятен гамәлгә кую җыелышы (круг, җыен) вәкаләт биргән зат (алга таба – вәкаләтле зат), төзелә торган казак җәмгыятенең уставын килештерү өчен, гамәлгә кую җыелышы (круг, җыен) казак җәмгыятен гамәлгә кую турында карар кабул иткәннән соң 14 календарь көн дәвамында Татарстан Республикасы Президентына казак җәмгыяте уставын килештерү турында тәкъдимнамә җибәрә.

Төзелә торган казак җәмгыятенең уставын килештерү турындагы тәкъдимнамәгә түбәндәгеләр теркәп бирелә:

казак җәмгыятен гамәлгә кую җыелышы (круг, җыен) утырышын чакыруга һәм уздыруга Россия Федерациясе Граждан кодексының 4 һәм 9[1] бүлекләрендә һәм коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеге өлкәсенә кагылышлы башка федераль законнарда билгеләнгән таләпләрнең үтәлүен раслый торган документлар күчермәләре;

гамәлгә кую җыелышының (кругның, җыенның) казак җәмгыяте уставын раслау турындагы карары кергән беркетмәсенең күчермәсе;

казак җәмгыяте уставы.

6. Татарстан Республикасы Президентына юллаганчы казак җәмгыяте уставы башка казак җәмгыяте атаманы белән килештерелергә тиеш, атап әйткәндә:

Россия Федерациясенең шулардан берсе Татарстан Республикасы булган ике һәм берничә субъекты территориясендә төзелә торган (гамәлдәге) округ (бүлек) казак җәмгыяте уставы – гаскәри казак җәмгыяте атаманы белән (әгәр гаскәри казак җәмгыяте Россия Федерациясенең әлеге казак җәмгыятьләре төзелә торган (гамәлдә булган) субъектлары территориясендә эшчәнлек алып барса);

Россия Федерациясенең шулардан берсе Татарстан Республикасы булган ике һәм берничә субъекты территориясендә эшчәнлек алып бара торган гаскәри казак җәмгыяте уставы – Бөтенроссия казак җәмгыяте атаманы белән.

Алга таба казак җәмгыяте уставын килештерүгә тәкъдимнамәгә казак җәмгыяте уставының әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән башка казак җәмгыятьләре атаманнары белән килештерелүе турында казак җәмгыяте атаманы яисә вәкаләтле зат имзасы белән расланган хатның күчермәсе теркәп бирелә.

7. Әлеге Нигезләмәләрнең 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән документлар күчермәләре казак җәмгыяте атаманы яисә вәкаләтле зат имзасы белән расланырга тиеш. Бит саны бердән артып киткән документлар (документлар күчермәләре) тегелергә, аларга бит саны куелырга һәм соңгы битнең арткы ягындагы тегәр өчен калдырылган урында казак җәмгыяте атаманы яисә вәкаләтле зат имзасы белән расланырга тиеш.

8. Казак җәмгыятенең уставын килештерүгә бирелгән документларны карап тикшерү һәм казак җәмгыяте уставын килештерү яисә килештерүдән баш тарту турындагы карар кабул итү Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан әлеге документлар алынган көннән соң 14 календарь көн дәвамында башкарыла.

Татарстан Республикасы Президенты кабул ителгән карар турында казак җәмгыяте атаманына яисә вәкаләтле затка тиешле рәсми хатка кул кую юлы белән язма рәвештә әлеге карар кабул ителгән көннән 14 календарь көннән дә соңга калмыйча хәбәр бирә.

Казак җәмгыяте уставын килештерүдән баш тарту турында карар кабул ителгәндә, хәбәрнамәдә мондый карарны кабул итүгә китергән сәбәпләр күрсәтелә.

9. Казак җәмгыяте уставын килештерүдән баш тарту өчен сәбәпләр түбәндәгеләр:

казак җәмгыяте югары идарә органының утырышын чакыруга һәм уздыруга Россия Федерациясе Граждан кодексының 4 һәм $9^1$ бүлекләрендә һәм коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеге өлкәсенә кагылышлы башка федераль законнарда, шулай ук казак җәмгыяте уставында билгеләнгән таләпләрнең үтәлмәве;

әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында каралган документларның бирелмәве яисә тулы булмаган тупланмасы бирелүе, аларны тутыру таләпләренең, бирү тәртибенең һәм срокларының үтәлмәве;

бирелгән документларда дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр булу.

10. Төзелә торган казак җәмгыяте уставын килештерүдән баш тарту сәбәпләре түбәндәгеләр:

казак җәмгыятен гамәлгә кую җыелышы (круг, җыен) утырышын чакыруга һәм уздыруга Россия Федерациясе Граждан кодексының 4 һәм $9^1$ бүлекләрендә һәм коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеге өлкәсенә кагылышлы башка федераль законнарда билгеләнгән таләпләрнең үтәлмәве;

әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында каралган документларның бирелмәве яисә тулы булмаган тупланмасы бирелүе, аларны тутыру таләпләренең, бирү тәртибенең һәм срокларының үтәлмәве;

бирелгән документларда дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр булу.

11. Казак җәмгыяте уставын килештерүдән баш тарту әлеге карарны кабул итүнең нигезле сәбәпләре бетерелгән очракта, Татарстан Республикасы Президентына казак җәмгыяте уставын килештерү турында тәкъдимнамәне

һәм әлеге Нигезләмәнең 4 һәм 5 пунктларында каралган документларны кабат юллауга тоткарлык була алмый.

Казак җәмгыяте уставын килештерү турында тәкъдимнамәне һәм әлеге Нигезләмәнең 4 һәм 5 пунктларында каралган документларны кабат юллау һәм бу тәкъдимнамә буенча карар кабул итү әлеге Нигезләмәнең 6 – 10 пунктларында күрсәтелгән тәртиптә башкарыла.

Казак җәмгыяте уставын килештерү турында тәкъдимнамәне һәм әлеге Нигезләмәнең 4 һәм 5 пунктларында каралган документларны кабат юллауның саны чикләнмәгән.

12. Татарстан Республикасы Президенты түбәндәгеләрне раслый:

казакларның Татарстан Республикасының ике яисә аннан артыграк муниципаль районы, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары территориясендә төзелә торган (гамәлдәге) район (йорт) җәмгыятьләре уставларын;

Татарстан Республикасы территориясендә төзелә торган (гамәлдәге) округ (бүлек) казак җәмгыятьләре уставлары.

13. Казакларның Татарстан Республикасының ике яисә аннан артыграк муниципаль районы, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары территориясендә төзелә торган (гамәлдәге) район (йорт) җәмгыятьләре уставлары Татарстан Республикасының тиешле муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыклары, шулай ук округ (бүлек) казак җәмгыяте атаманы белән килештергәннән соң раслана (әгәр округ (бүлек) казак җәмгыяте әлеге казак җәмгыятьләре төзелә торган Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып барса).

14. Татарстан Республикасы территориясендә төзелә торган (гамәлдәге) округ (бүлек) казак җәмгыятьләре уставлары аларны гаскәри казак җәмгыяте атаманы белән килештергәннән соң раслана (әгәр гаскәри казак җәмгыяте әлеге казак җәмгыятьләре төзелә торган (гамәлдә булган) Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып барса).

15. Гамәлдәге казак җәмгыяте уставын раслау өчен бу җәмгыятьнең атаманы казак җәмгыятенең килештерелгән уставын алган көннән соң биш календарь көн дәвамында Татарстан Республикасы Президентына казак җәмгыяте уставын раслау турында тәкъдимнамә юллый.

Казак җәмгыяте уставын раслау турында тәкъдимнамәгә түбәндәгеләр теркәп бирелә:

казак җәмгыяте югары идарә органының утырышын чакыруга һәм уздыруга Россия Федерациясе Граждан кодексының 4 һәм $9^1$ бүлекләрендә һәм коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеге өлкәсенә кагылышлы башка федераль законнарда, шулай ук казак җәмгыяте уставында билгеләнгән таләпләрнең үтәлүен раслый торган документлар күчермәләре;

казак җәмгыяте югары идарә органының бу казак җәмгыятенең уставын раслау турында карары кергән беркетмә күчермәсе;

казак җәмгыяте уставының әлеге Нигезләмәнең 13 һәм 14 пунктларында күрсәтелгән вазыйфаи затлар белән килештерелүе турында хатлар күчермәләре;

казак җәмгыяте уставы кәгазь чыганакта һәм электрон рәвештә.

16. Вәкаләтле зат казак җәмгыятенең килештерелгән уставын алган көннән соң биш календарь көн дәвамында Татарстан Республикасы Президентына төзелә торган казак җәмгыяте уставын раслау өчен казак җәмгыяте уставын раслау турында тәкъдимнамә юллый.

Казак җәмгыяте уставын раслау турындагы тәкъдимнамәгә түбәндәгеләр теркәп бирелә:

казак җәмгыятен гамәлгә кую җыелышы (круг, җыен) утырышын чакыруга һәм уздыруга Россия Федерациясе Граждан кодексында һәм коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеге өлкәсенә кагылышлы башка федераль законнарда билгеләнгән таләпләрнең үтәлүен раслый торган документлар күчермәләре;

казак җәмгыяте уставын раслау турында гамәлгә кую җыелышы (кругы, җыены) карары кергән беркетмә күчермәсе;

казак җәмгыяте уставының әлеге Нигезләмәнең 13 һәм 14 пунктларында күрсәтелгән вазыйфаи затлар белән килештерелүе турында хатлар күчермәләре;

казак җәмгыяте уставы кәгазь чыганакта һәм электрон рәвештә.

17. Әлеге Нигезләмәләрнең 15 һәм 16 пунктларында күрсәтелгән документлар күчермәләре казак җәмгыяте атаманы яисә вәкаләтле зат имзасы белән расланырга тиеш. Бит саны бердән артып киткән документлар (документлар күчермәләре), электрон рәвештә бирелгән документлардан кала, тегелергә, аларга бит саны куелырга һәм соңгы битнең арткы ягындагы тегәр өчен калдырылган урында казак җәмгыяте атаманы яисә вәкаләтле зат имзасы белән расланырга тиеш.

18. Әлеге Нигезләмәнең 15 һәм 16 пунктларында күрсәтелгән документларны карап тикшерү һәм казак җәмгыяте уставын раслау яисә килештерүдән баш тарту турындагы карар кабул итү Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан әлеге документлар алынган көннән соң 30 календарь көн дәвамында башкарыла.

Татарстан Республикасы Президенты кабул ителгән карар турында казак җәмгыяте атаманына яисә вәкаләтле затка тиешле рәсми хатка кул кую юлы белән язма рәвештә әлеге карар кабул ителгән көннән 14 календарь көннән дә соңга калмыйча хәбәр бирә.

Казак җәмгыяте уставын раслаудан баш тарту турында карар кабул ителгәндә хәбәрнамәдә мондый карарны кабул итүгә китергән сәбәпләр күрсәтелә.

Казак җәмгыятенең уставын раслау Татарстан Республикасы Президенты боерыгы нигезендә рәсмиләштерелә, аның күчермәсе казак җәмгыяте атаманына яисә вәкаләтле затка әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән тапшыру турында хәбәрнамә белән бергә җибәрелә.

19. Гамәлдәге казак җәмгыяте уставын раслаудан баш тарту өчен сәбәпләр түбәндәгеләр:

казак җәмгыяте югары идарә органының утырышын чакыруга һәм уздыруга Россия Федерациясе Граждан кодексында һәм коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеге өлкәсенә кагылышлы башка федераль законнарда, шулай ук казак җәмгыяте уставында билгеләнгән таләпләрнең үтәлмәве;

әлеге Нигезләмәнең 15 пунктында каралган документларның бирелмәве яисә тулы булмаган тупланмасы бирелүе, аларны тутыру таләпләренең, бирү тәртибенең һәм срокларының үтәлмәве;

бирелгән документларда дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр булу.

20. Төзелә торган казак җәмгыяте уставын раслаудан баш тарту сәбәпләре түбәндәгеләр:

казак җәмгыятен гамәлгә кую җыелышын (кругны, җыенны) чакыруга һәм уздыруга Россия Федерациясе Граждан кодексында һәм коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеге өлкәсенә кагылышлы башка федераль законнарда билгеләнгән таләпләрнең үтәлмәве;

әлеге Нигезләмәнең 16 пунктында каралган документларның бирелмәве яисә тулы булмаган тупланмасы бирелүе, аларны тутыру таләпләренең, бирү тәртибенең һәм срокларының үтәлмәве;

бирелгән документларда дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр булу.

21. Казак җәмгыяте уставын килештерүдән баш тарту әлеге карарны кабул итүнең нигезле сәбәпләре бетерелгән очракта, Татарстан Республикасы Президентына казак җәмгыяте уставын килештерү турында тәкъдимнамәне һәм әлеге Нигезләмәнең 15 һәм 16 пунктларында каралган документларны кабат юллауга тоткарлык була алмый.

Казак җәмгыяте уставын раслау турында тәкъдимнамәне һәм әлеге Нигезләмәнең 15 һәм 16 пунктларында каралган документларны кабат бирү, бу тәкъдимнамә буенча карар кабул итү әлеге Нигезләмәнең 17 – 20 пунктларында күрсәтелгән тәртиптә башкарыла.

Казак җәмгыяте уставын килештерү турында тәкъдимнамәне һәм әлеге Нигезләмәнең 15 һәм 16 пунктларында каралган документларны кабат юллауның саны чикләнмәгән.

22. Татарстан Республикасы Президентына килештерүгә яисә раслауга кертелә торган казак җәмгыяте уставының титул битендә тиешенчә килештерү яисә раслау грифларын куюны күздә тоту тәкъдим ителә.